**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**СОВЕТ ФЕДОРОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
422380 с. Федоровка, ул.Школьная, 1

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТӘТЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ФЕДОРОВКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**
422380 Федоровка авылы, Школьная урамы, 1

тел. (84373) 5-70-15, факс 57-0-15; e-mail: Fedor@tatar.ru
ОГРН 1021606559875, ИНН/КПП 1638001688/163801001

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**
**24 .06. 2024** **№ 40-1**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында»2023 елның 16 июнендәге 29-1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пунктына, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 номерлы Федераль законга, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45 ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, «Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына ярашлы рәвештә, Федоровка авыл җирлеге Советы карар кылды:

1. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге Советының «җирле салымнар суммалары өлешендә бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләрен билгеләү турында» 2023 елның 16 июнендәге 29-1 номерлы карарының 1 пункты түбәндәге эчтәлектәге 8 пунктчасы белән тулыландырылсын:

8) физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.

2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында һәм хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга (PRAVO.TATARSTAN.RU).

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Федоровка авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

**Җитәкче** **М.Ю. Никонорова**